ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВ

КЫЗЫК ДӨНЬЯ

ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВ

КЫЗЫК ДӨНЬЯ

Шигырьләр

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ 1974

С(Тат)2
3—82

Хvдожнигы Т. И. Усманов

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

З $\frac{0761-196}{М\ 132\ (03)-74}$ 160—74

© Татарстан китап нәшрияты, 1974.

СӨЕНДЕРСӘМ...

Егылганда иптәшемә
Сузсам кулым,
Өлкәннәргә хөрмәт белән
Бирсәм урын,
Я берәрсе, мине сөеп,
Рәхмәт дисә,
Улы кебек якын итеп
Кулын бирсә —
Горурлыктан күңелем тула,
Күккә ашкан кебек булам.

Әнкәемне «бишле» алып
Сөендерсәм,
Күрше картка чишмәбездән
Су китерсәм,
Ә ул, мине сөя-сөя,
Улым, дисә,
Битләремә аның олы
Кулы тисә —
Горурлыктан күңелем тула,
Күккә ашкан кебек булам.



КҮЗЛӘРЕМНӘН КҮРГӘН

Әнкәм бүген кояш кебек
Каршы алды елмаеп.
Минем «бишле» алганымны
Әйткәннәрдер, мөгаен.

Юк шул, «бишле» алганымны
Белмәгән ул беркемнән.
Ишек ачып керүемә,
Күзләремнән ул күргән.

ӘНИЕМ КУЛЛАРЫ

Әнкәм кулын, юкса, төнлә
танийм —
Сөялләнеп беткән, ярылган...
Ник соң аның хакта газетага
«Алтын куллы» диеп язылган?



ЙОЗАК ТҮГЕЛ

Ялгыз калырга
Һич тә теләми,
Беркая мине
Өйдән җибәрми.

Юк, йозак түгел,
Ул — минем энем.
Саклый ул шулай
Көн буе мине.



ХӘЙЛӘПРҮШ ЧИРЕ

Өмә булса, Абдулла
Авыруга салына.
Иптәшләре килсәләр,
Тизрәк юрган ябына.
Кем керсә дә янына,
Сызланып башын тота:
«Һай,— ди,— хәлем бик авыр,
Һай, башкаем авырта!»
Килде доктор беркөнне
Аның хәлен белергә.
Авыруны карарга,
Бер-бер чара күрергә.
Доктор озак карады,
Күзлеген басып киде:
«Хәйләпрүш чире йоккан,
Дәвасы — хезмәт»,— диде.

КУЯН УЯНДЫ

Уянды да бер куян
Кояш чыккан чагында,
Юды колак-күзләрен
Салкын үлән чыгында.
Бөтен тәне чыланды,
Аңа салкын тоелды.
Һәм тиз генә аланда
Ул йөгереп җылынды.

КАРАП ТОРА МАЛАЙЛАР

Җылы яңгыр явып үткәч,
Чыктылар да урамга,
Тотындылар малайлар
Көймә йөртеп уйнарга.
Төрле төсләр хасил булды
Шул чак урман өстендә.
Юл-юл төсләр арасында
Юктыр нинди төс кенә!
Ничек итеп мондый чакта
Күңел барсын уйнарга?
Авыз ачып малайлар
Карап тора шуңарга.
— Шаккатмагыз,— ди Әхмә
Сөйләнә күп белгәндәй,—
Салават күперен шулай
Җилләтергә элгәннәр.

ЯҢГЫРКАЕМ

Яңгыркаем, яумый тор,
Зинһар, мине аңлый күр.
Таммый тор син чебигә
Алып кергәнче өйгә.
...Өйдә инде чеби дә,
Кайтты өйгә әби дә.
Яңгыркаем, яу инде,
Хәзер ярый тамсаң да.
Ачуланмыйм мин сиңа,
Төне буе яусаң да.

МАЙМЫЛЛАР ЯНЫНДА

Йолдыз белән икәүләп
Зоопаркка килдек.
Маймыллар шундый кызык,
Рәхәтләнеп бер көлдек.
Әле биеп китәләр,
Аннан бүләк көтәләр.
Кетәләр чикләвекләр...
Маймыллар ут кебекләр.
Ә чикләвек ярырга
Алар бигрәк тә өлгер,
Тик биреп кенә өлгер.
Бер минут та үтмәде,
Бушап калды кесәләр.
Ә маймыллар китмиләр,
Һаман бүләк көтәләр.
Кайсыдыр бер шаяны,—
Уйлап тапкан каян ул? —
Чикләвек төшен алып,
Ыргытты буш кабыгын.
Күрсәгез иде шунда
Маймылның кылануын!
Иң элек җайлап кына
Кабыкларны алды да,
Буш кабыклар арасына
Черки тотып салды да,
Сузды шундук бүләген
Теге шаян Сабирга.
Тик бүләкне Сабир гына
Никтер кыймый алырга.

БЕЛӘ

Әбинең кәҗәсе бар,
Вилнең сөт эчәсе бар.
Ак булсын тешем, ди ул.
Нык булсын тешем, ди ул.
Шуңа сөт эчәм, ди ул
Теше нык булсын өчен,
Теше ак булсын өчен,
Ул сөт кирәген белә,
Тик кәҗәгә бер уч печән
Бирә белми ул менә.



АЙЛЫ КИЧТӘ

Әнкәсенең канаты
Ябылмыйча калган да,
Бер чебигә бер йолдыз
Күренә, ди, һаман да.
Каурыйлар арасыннан
Җемелди, ди, бу йолдыз.
Чеби шуңа кызыгып,
Утыра, ди, йокысыз.
Бу йолдызны чукырга
Чеби уйлап куя, ди.
Тик кирәкми, калсын, ди,
Тамагым бик туйган, ди.

ОШАМАДЫ ВӘЛИГӘ

Сөендермәк булды Кәли
Туган көндә Вәлине.
Бүләк алып кайтты Кәли,
Тәбрикләде Вәлине.
Бүләкне алгач, куанып
Кочты Вәли Кәлине.
— Җибәр әле,— диде Кәли,—
Бик арыдым мин, Вәли.
Кермәгән җир калмады,
Акча җитмәс бүләккә дип,
Кинога да бармадым...—
Китте шулай зарланып.
— Алайса,— диде Вәли,—
Илтеп бир аны, Кәли.
— Ә нигә? — диде Кәли.
Уйлап карыйк: ә нигә
Кәлинең бу бүләге
Ошамады Вәлигә?

ИКЕ ДУС

Ике дус, ди, берара
Сөйләшә, ди, үзара:
— Ай-һай, Нил, шәп егет син!
— Әйе шул, шундый шул мин...
— Бар үзеңдә акыл да,
Үзең шундый батыр да.
— Быел әле сабантуйда
Чыкмак булам батырга.
— Яратам сине, Нилкәй!
— Без бит дуслар, Кәримкәй!
— Тик нигә син нәниләрне
Кимсетәсең, Нил, алай?
— Телеңне тый син, малай!

ЭЧТӘЛЕК

Сөендерсәм... 3
Күзләремнән күргән 5
Әнием куллары 6
Йозак түгел 7
Хәйләпрүш чире 8
Куян уянды 9
Карап тора малайлар 10
Яңгыркаем 11
Маймыллар янында 12
Беләә 13
Айлы кичтә 14
Ошамады Вәлигә 15
Ике дус 16

Зиятдинов Фарсель Сахапович

ЧЕМ ПРЕКРАСЕН МИР?

Стихи

(на татарском языке)

Редакторы *Резеда Вәлиева*

Художество редакторы *Азат Садыйков*

Техник редакторы *Вера Галкина*

Корректоры *Сувәйдә Мөхәммәдьярова*

Наборга бирелде 29/XI-1973 ел. Басарга кул куелды 22/V-1974 ел. Типография кәгазе № 2, 70×90$^1/_{16}$. Учетн.-изд. таб. 1,16. Якынча басма таб. 1,17. Тираж 10 000. Заказ Я-554. Бәясе 7 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты.
Казан, Бауман ур., 19.

7 тиен.